**Республика Татарстан**
**Менделеевский муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Татарско-Челнинского сельского поселения**

**Татарстан Республикасы**
**Менделеев муниципаль районы**
**Татар-Чаллысы авылы җирлеге**
**башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 15** **30.06.2021**

«Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең 2021 ел өчен һәм 2022, 2023 елларның планлы чорына салым чыгымнары исемлеген раслау турында»

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 18 маеннан «2020 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 9 нчы номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибенең 5 нче пункты нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең 2021 ел өчен һәм 2022, 2023 елларның планлы чорына беркетелгән салым чыгымнары исемлеген расларга.
2. Әлеге карарныавыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:/ mendeleevsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырып халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Менделеевск муниципаль районы

Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.

РАСЛАНДЫ

Менделеевск муниципаль районы

Татар Чаллысы авыл җирлеге

Башкарма комитетының

2021 елның 30 июнендәге

15 номерлы карары белән

Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең 2021 ел өчен һәм 2022, 2023 елларның планлы чорына беркетелгән салым чыгымнары исемлеге

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлдә булу датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлекнең норматив актларында билгеләнгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча бүтән преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең исеме | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 144 нче номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 12 декабрендәге 121 нче номерлы карары | Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә: 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булганнарны | 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән гражданнар | 01.01.2019 | 01.01.2019 | Чикләнмәгән (ташламалар туктатылу датасына кадәр) | Билгеләнмәгән | Торак йорт, күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирлар милекчеләренә исәпләнгән салым суммасын киметүче мөлкәткә салым буенча ташлама | Социаль |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 144 нче номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 15 мартындагы 133 нче номерлы карары | Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы. Салым ташламасына салым түләүченең хокукларын раслау Салым кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла. Салым ташламасы бирү турында гариза формасы һәм аны тутыру тәртибе, мондый гаризаны электрон рәвештә тапшыру форматы салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.» | Физик затлар | 01.01.2019 | 01.01.2019 | Чикләнмәгән (ташламалар туктатылу датасына кадәр) | Билгеләнмәгән | Торак йорт, күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирлар милекчеләренә исәпләнгән салым суммасын киметүче мөлкәткә салым буенча ташлама | Социаль |
| 2 | «Җир салымы турында» 2020 елның 24 мартындагы 164 нче номерлы карары | Салым түләүче сайлау буенча бер җир участогына карата | Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, Советлар Союзы Геройлары, | 01.01.2021 | 01.01.2021 | Чикләнмәгән (ташламалар туктатылу датасына кадәр) | Билгеләнмәгән | салым салудан азат итү рәвешендәге җир салымы буенча салым ташламалары | Социаль |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары; | | | | | | |
| | | | Оешмалар һәм учреждениеләр | 01.01.2021 | 01.01.2021 | Чикләнмәгән (ташламалар туктатылу датасына кадәр) | Билгеләнмәгән | граждан күмү белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата салым салудан азат итү рәвешендәге җир салымы буенча салым ташламалары | Социаль |
| | | | Оешмалар һәм учреждениеләр | 01.01.2021 | 01.01.2021 | Чикләнмәгән (ташламалар туктатылу датасына кадәр) | Билгеләнмәгән | гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата салым салудан азат итү рәвешендәге җир салымы буенча салым ташламалары (урман парклары, парклар, скверлар, шоссе, урамнар, тыкрыклар, юллар, мәйданнар, күперләр, чишмәләр, су объектлары, һәйкәлләр, Мактау такталары, балалар мәйданчыклары, контейнер мәйданчыклары) | Социаль |
| | | | Менделеевск муниципаль районы бюджетыннан | 01.01.2021 | 01.01.2021 | Чикләнмәгән (ташламалар туктатылу датасына кадәр) | Билгеләнмәгән | күп фатирлы төзелеш һәм торак төзелеше өчен билгеләнгән | стимуллаштыручы |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | финанслана торган бюджет һәм автоном учреждениеләр, казна, җирле үзидарә органнары | | | | | торак пунктларның җирләре өлешендә салым салудан азат итү рәвешендәге җир салымы буенча салым ташламалары | |